СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*12 август, 1998 ел.*
*ЧӘРШӘМБЕ*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 91 (8248)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

## ИГЕНЧЕЛЕК КАНУННАРЫН БОЗАРГА ЯРАМЫЙ

### *ХАКИМИЯТТӘ КИҢӘШМӘ*

Узган җомга көн хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллин хуҗалык, агропромышленность комплексының эшкәртү предприятиеләре, авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең баш белгечләре белән киңәшмә үткәрде. "Яхшы яңгыр белән котлыйм үзегезне!" - эшче киңәшмәне әнә шулай гадәти булмаганча башлап җибәрде ул. Чыннан да, бу арада узган яңгырлар бигрәк тә чөгендерчеләребезнең күңелен үстереп җибәрде. Августта һәм сентябрь башларында тагын шундый берничә яңгыр булса зыян итмәячәк әле - җиребез шифалы дымга бик сусады бит.

Район җитәкчелеге бөртекле һәм бөртекле - кузаклыларны урып - җыюның темплары акрын булуга борчыла. Уңыш тотылган матди ресурслар һәм куелган хезмәтне акларлык булмаса да, бар кадәресен оешкан төстә һәм иң кыска срокларда җыеп алырга кирәк. Шуңа күрә дә урак конвейеры даим игътибар сорый - бу мәсьәләдә төп җаваплылык хуҗалык рәисләрендә.

Ф.С.Сибагатуллин кайбер хуҗалыкларда туфрак эшкәртү технологиясе таләпләрен санга сукмауларына һәм башкарыла торган агрочараларның сыйфатына зур борчылуын белдерде. Быел соңгы ун елда беренче тапкыр туңга сөрүне августта төгәлләргә һәм туфракны чүп үләннәреннән һәм корткычлардан саклау системасын тулы комплексында кулланырга мөмкинлек бар. Бу исә җирнең уңдырышлылыгын күтәрүгә алшарт тудырачак. "Сыйфатка күбрәк игътибар бирергә кирәк!" - хакимият башлыгы шундый бурыч куйды. - Уҗым культураларын рәтләп йомшартылмаган һәм эшкәртелмәгән җиргә чәчү - җинаять. Икмәк җансызлыкны гафу итми - киләсе ел уңышында бик тиз чагылачак ул. Менә бит быел да басу читләрендә үсемлекләр куерак булып та, эчкәрәк кергән саен бөтенләй башка хәлгә тап булу очраклары аз түгел. Димәк, кыр һәр урында да бердәй эшкәртелмәгән, ә җир, аңлашыла ки, моның белән килешми. Кырларның күз алдындагы басу читен генә түгел, ә һәр карышны җиренә җиткереп һәм дөрес иттереп эшкәртергә кирәк, диде хакимият башлыгы һәм шуны санга сукмаучы кайбер хуҗалык җитәкчеләрен бастырды да. Бу уңайдан туфрак эшкәртү технологиясенең барлык таләпләрен үтәүгә карата кискен һәм бәхәссез таләпләр куелды. Уңыш өчен көрәштә суперэлита сортлы орлыкларны куллану кебек мөһим мәсьәлә дә кузгатылды. Быел район 600 тоннадан артык орлык алыштырырга мөмкинлек тапты.

Киңәшмәдә хуҗалыкларны реформалаштыру темасы да кузгатылды. Җиргә хуҗа эзләү бүген бик авыр эш, һәм кайчагында ирешелгән нәтиҗәләрдән дә чигенергә туры килүе икеләтә кызганыч. Бу очракта Ф.С.Сибагатуллин элеккеге "Москва" хуҗалыгы мисалын үкенеч белән телгә алып үтте. 1997 елда өч кооператив оешканнан соң монда эшләр сизелерлек алга киткән иде. Чәчүне алар бүтәннәрдән алда бетерделәр, уракны һәм туңга сөрүне иң оптималь срокларда башкарып чыктылар. Илюткино механизаторлары көзен әле "Игенче" хуҗалыгына да булыштылар. Дәүләткә бодайны элеккеге еллардагыдан өч тапкыр күбрәк саттылар. Хезмәт дисциплинасы ныгыды, гомуми энтузиазм да күтәрелде. Ни өченме? Игенчеләр үз язмышларын үз кулларына алдылар һәм инде күршегә сылтамый башладылар. Тик менә быел КХАга рәис сайлап куйдылар да... көйләнгән механизм чыгымлый башлады. Бар хикмәт һәр коллективның эштәге ахыр нәтиҗә өчен җаваплылыгы кебек төп җанлы форма бозылуда дип уйларга кирәк. Җиргә һәм милеккә хуҗа булып эшләүнең беренче күркәм нәтиҗәләре күренгән икән, яңадан элеккеге алымнарга кайтырга ярамый шул. Хәзерге базарның законнары бөтенләй башка.

Хакимият башлыгының чыгышында ягулык - майлау материалларын тотуга бәрәкәтле мөнәсәбәт мәсьәләләре дә яктыртылды. Бу эштә ул "Сөлчә" хуҗалыгындагы җитешсезлекләрне билгеләп үтте, агымдагы барлык проблемаларны хәл итүдә һәм башкару дисциплинасын ныгытуда һәр хуҗалык җитәкчесенең шәхси җаваплылыгын көчәйтү кирәклегенә басым ясады.

Аннары киңәшмәдә катнашучылар "Киекле" хуҗалыгы кырын карадылар. Агротехниканың барлык таләпләрен үтәп эшкәртелгән ул кыр күрер күзгә әйбәт кенә һәм монда яхшы уңышка өмет итәргә мөмкин. Шулай итеп, хуҗалык җитәкчеләре җир белән ничек эш итү үрнәген күрделәр. Инде урыннарда эшне активлаштырасы гына калды.

**Т.НАЗАРОВА.**

## *"УҢЫШ - 98"*
## *МАТБУГАТ ҮЗӘГЕ ХӘБӘР ИТӘ*



***Бу яңгырлар бик көтелгән һәм шифалы булса да, урып - җыю конвейерының эшен шактый тоткарлады. Соңгы өч - дүрт көндә игене суктырылган мәйданнар "Киекле", Мичурин исемендәге хуҗалыкларда гына шактый ук, "Заветы Ильича", РСУ һәм шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында гына сизелерлек ишәйде. Мичуринлылар - бүгенгә сабан бодаен иң күп - 150 гектар мәйданда суктыручылар, "Киекле" һәм Хафизов исемендәге хуҗалыкларда ул мәйданнар йөзәр гектар. Мичуринлылар бүгенгә бодайның һәм суктырылган барлык ашлыкның тулай җыемы буенча да иң алда баралар.***

***Кичәге көнгә көзге чәчү Хафизов исемендәге хуҗалыкта 90, "Киекле", "Төрнәс" һәм Мичурин исемендәге хуҗалыкларда 40 - 50шәр гектарда уздырылды. Район буенча барлыгы сигез хуҗалык бу эшне башлап куярга өлгерде.***

***Туңга сөрелгән мәйданнар бу дүрт көндә икеләтә артты. Сөт - май комбинаты һәм "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыкларыннан кала барлык хуҗалыкларда да бу чарага керештеләр инде. "Татарстан", Мичурин исемендәге һәм Синдряков исемендәге хуҗалыкларда 400әр гектар җирне эшкәртергә өлгерделәр. "Заря", шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында туңга сөреләсе мәйданнарның биштән берենә якыны эшкәртелгән. Шул ук вакытта соңгы өч - дүрт көндә тракторлары кырга чыгып та карамаган хуҗалыклар бар.***

***Терлек азыгы хәзерләүгә килсәк, Синдряков исемендәге хуҗалыкта иң күп - 58 тонна витаминлы үлән оны бар бүгенгә, монда печәннең еллык ихтыяҗ чамасы, сенажның пландагыдан яртысыннан күбрәк булуын исәпкә алсак, хуҗалыкта бер шартлы терлеккә әзерләнгән азыкның 13 центнерга якын булуы гаҗәп түгел. Дөрес, соңгы күрсәткеч 17 -19 центнер булган хуҗалыклар да бар, тик малларның санынннан чыгып караганда, азыкның төрен дә, туклыклылыгын да, ахыр чиктә, базлардагы сенажның былтыргымы, быелгымы булуын да исәпкә алырга кирәктер. Азык төре дигәннән, инде кукурузның да силоска дигәнен җыя башларга вакыт - шактый катып киткән коры үләннәрне сусыл кукуруз массасы белән катнаштырып базга салу максатка ярашлы.***

## БӘЙРӘМГӘ ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ

***30нчы августта Татарстан Республикасы үзенең мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул итүенә сигез ел тула.***

Эшче комиссия районда бәйрәм үткәрү буенча тематик программа әзерли дә башлады инде. Сәүдә хезмәте, үзешчәннәр концерты, спорт, мавыктыргыч уеннар, төрле конкурслар һәм ярышлар, атаклы якташлар белән очрашу - болар һәммәсе дә тантана программасына кертеләчәк. Бәйрәм үткәрелү урыны әлегә билгеле түгел, ә менә 30нчы августның айның соңгы якшәмбесенә туры килүе тантанага күп халыкны җыячак инде, монысы шиксез.

## БУРЫЧНЫ ТҮЛӘРГӘ КИРӘК

Узган җомга көн хакимият башлыгы урынбасары Н.Б.Мөлеков торак йортларны газлаштыру буенча башкарылган эшләр өчен авыл халкыннан акча җыюны тәэмин итү хакында җирле үзидарә Советлары рәисләре белән киңәшмә үткәрде. Сөйләшүнең темасын тормыш үзе әйтеп тора: йортларга челтәр газы кергән, ә газ кертүчеләргә бурыч түләнмәгән - авыл кешесенең гаилә бюджеты ярлы. Киңәшмәдә бу проблеманы хәл итү юллары турында эшлекле сөйләшү булды. Анда шулай ук мәктәпләрне, клубларны, фельдшер-акушерлык пунктларын һәм социаль - мәдәни багланышлы башка объектларны газлаштыруны дәвам итү перспективалары да тикшерелде.

Киңәшмә эшендә "Востокмонтажгаз" АҖ генераль директоры урынбасары Н.П.Золотов, икенче төзү идарәсе (Отрадный шәһәре) начальнигы Ф.Н.Гизитдинов, халык депутатларының Нурлат берләштерелгән Советы, авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең җаваплы хезмәткәрләре катнашты.

## ЯКТАШЫБЫЗГА - ОЛЫ БҮЛӘК

Кол Гали исемендәге халыкара бүләкләр комитетының махсус комиссиясе, 1998 ел өчен Кол Гали исемендәге халыкара бүләкләргә тәкъдим ителгән кандидатуралар һәм аларның хезмәтләре белән танышып чыкканнан соң, 1998 ел өчен Кол Гали исемендәге халыкара бүләкләрне өч кешегә бирергә карар чыгарды. Бүләкләнүчеләр арасында якташыбыз **ГАЛИУЛЛИН Тәлгат Нәби улы** да бар. Бу бүләккә ул "Дәгъва" һәм "Замана балалары" дигән китаплары өчен лаек булды.

Күренекле әдип, фән һәм җәмәгать эшлеклесе, танылган галим якташыбызны олы бүләк белән ихлас күңелдән котлыйбыз.

## САТКАНЫ КҮПМЕ, САУГАНЫМЫ?

***Саннарның беренче баганасы - җиде айда дәүләткә сатылган, икенчесе - савылган сөт (бер сыерга күчереп исәпләгәндә килограммнарда).***

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| "Дуслык" | 3483 | 4204 | РСУ ярд. хуҗ. | 1507 | 1842 |
| "Кондырча" | 3375 | 4074 | "Чулпан" | 1396 | 1921 |
| Мичурин исем. | 2560 | 3221 | М. Җәлил исем. | 1361 | 2222 |
| Синдряков исем. | 2518 | 2991 | "Татарстан" | 1322 | 1735 |
| "Сөлчә" | 2305 | 2857 | "Игенче" | 1233 | 1575 |
| "Киекле" | 2121 | 2463 | "Үрнәк" | 1220 | 1761 |
| "Родина" | 2013 | 2367 | "Таң" | 1195 | 1657 |
| Хафизов исем. | 1983 | 2549 | Илюткино - 3 | 1150 | 2075 |
| Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 1976 | 2524 | Илюткино - 2 | 1150 | 2073 |
| "Чирмешән" | 1637 | 2263 | "Алга" | 1119 | 1459 |
| "Төрнәс" | 1624 | 1993 | "Комбайн" | 1060 | 1332 |
| Кузнецов исем. | 1606 | 2053 | "Нур" кооп. | 849 | 1583 |
| "Рассвет" | 1595 | 2684 | Нефтебаза ярд. хуҗ. | 785 | 1374 |
| "Заветы Ильича" | 1573 | 2292 | "Руслан" кооп. | 389 | 731 |
| "Заря" | 1570 | 1930 | **Район буенча** | **1651** | **2168** |

## *МӘКТӘП БАЛАЛАРЫН БҮЛӘКЛӘР КӨТӘ*

Фломастерлар, буяулар, конструкторлар, бер тартма пластилин, рәсем альбомы, дәфтәрләр комплекты һәм күп кенә башка нәрсәләр - әниләре эшсез статусына ия булган 202 I - III класс укучылары быел шундый бүләк алачак. Нурлат хезмәт һәм мәшгульлек үзәге балаларга менә шундый бик кирәкле бүләк әзерләде.

*Коммуналь хуҗалыкта үзгәрешләр*

# МПП, ЖЭУ ҺӘМ БЕЗ

***Озакламый торактан файдаланучылар фатирга түләү өчен еракка йөрмәячәк, бернинди кыенлыксыз бу мәсьәләне үз торак - эксплуатация идарәләрендә хәл итәчәкләр - МПП начальнигы Ә.К.ГАЙНУЛЛИН шулай дип тынычландыра.***

***Торак - эксплуатация идарәсе (кыскача ЖЭУ) нәрсә ул, кая урнашкан һәм фатир өчен түләүләрне җыюдан башка тагын нияләр белән шөгыльләнә? Без МПП начальнигыннан бу хактагы мәгълүматны җентекләбрәк алдык.***

Шәһәр территориясен ЖЭУларга бүлеп хезмәт күрсәтү зур шәһәрләрнең эш практикасында күптәннән кулланыла. Норма буенча бер ЖЭУ 50 мең кв.метр торакка хезмәт күрсәтергә тиеш. Нурлатта ведомстводагы торак фондларының МПП балансына күчүе аркасында, биредә торак мәйданы 235 мең кв. метрдан артып китә һәм аны ЖЭУларга бүлеп хезмәт курсәтү ихтыяҗын тудыра. Нурлатның статусын үзгәрткәннән соң бу эш тагын да актуальрак төс ала. Торак мәйданыннан чыгып, 6 ЖЭУ оештырырга ниятлиләр. Хәер, шуларның 4се эшчеләр, хезмәткәрләр белән комплектланган, бүгенге көндә эшлиләр дә инде - үзләре беркетелгән территорияләрдә йорт ян... ишегалларын, газоннар... җыештыралар, аларны тәртиптә тотуны кайгырталар, коммуналь хезмәтләр күрсәтәләр. Әлегә бары тик касса аппаратлары һәм башка шундый кирәк - яраклар булмау аркасында түләүләрне җыя алмыйлар. Шикәр заводы, НГЧ, "Сельхозтехника", "Татагропроммехмонтаж", "Агрохимсервис" торак фондлары МПП балансына күчеп бетә алса (йортларның, канализация, су үткәрү системаларының төзексез хәлдә булуы сәбәпле, аларның МППга тапшырылуы һаман да чигерелә бара), 5 - 6нчы ЖЭУлар да оешачак, ди предприятие начальнигы.

Һәр ЖЭУ штатында мастер, паспортчы, кассир, эретеп ябыштыручы, слесарьлар, дворниклар бар - барлыгы 15 кеше. Урнашу урыннары - подваллар. Өчесенең адресы төгәл билгеле (Козлов урамы,3, Дружба, 75, Совет,124) булса, калган өчесенеке әлегә анык түгел, Школьная урамында, шикәрчеләр һәм тимер юл бистәләрендә булачак, диләр. Әлегә подвалларда телефоннар юк, тик киләчәктә кертергә ниятлиләр.

Шунысын да әйтергә кирәк, ЖЭУларны оештыру белән МПП слесарьлар, дворниклар һәм башка белгечлекләр буенча штатны ике тапкырга арттырды.Шәһәрнең статусын үзгәртүе ЖЭУлардан тыш тагын бер службаны киңәйтергә мөмкинлек бирә. Дөрес, аның да вазифалары тегеләрнекенә тиңдәш, бары тик административ биналар тирәсендә тәртип һәм чисталык булдыру белән, төзекләндерү һәм газоннарны яшелләндерү белән мәшгуль ул.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**



***Кышка терлек азыгы әзерләргә әле вакыт булса да, запасларны исәпләр, ашыгыр чак хәзер. Муса Җәлил исемендәге кумәк хуҗалыкта бу мәсьәләгә аеруча җаваплылык белән карыйлар быел. Ел азыкка муллыгы белән бик кинәндермәсә дә, теләк һәм тырышлык булганда җыярга мөмкин икән. Бикүлелеләр дә печәнне тиешлененең 85 процентын җыйдылар,45 тонна витаминлы үлән оны, шулкадәр үк яфрак азык һәм 8 тонна дәвалау үләннәре әзерләделәр. Бүгенге көндә салам эскертләргә өелә һәм сенаж салына, икесе дә норманың яртысына җиткерелде инде. Нәтиҗәдә бүгенге көнгә бер шартлы терлеккә гомуми әзерләнгән азык берәмлеге 13,1 центнерны тәшкил итә. Рәсемдәге механизатор Васыйл ГЫЙЛЬФАНОВны фотохәбәрчебез Н.АЗИЗОВ кызу печән өстендә төшереп алган иде. Ул азык әзерләүдә башыннан алып бүгенге көнгәчә эшли. Хәзер исә өлгер "Беларусь"е белән сенажга тапаткан үләннәр ташый.***

*Яшүсмер һәм җәмгыять*

# ҖӘЙЛӘРЕ БУШКА УЗМАДЫ

Җәй айлары җиттеме, ата - анага яңа борчу өстәлә: баласын кая илтергә?Гаиләдә яшүсмер булганда бу мәсьәлә аеруча актуаль: урам аны үзенә чакыра, ә анда эшсез - шөгыльсез, вакытын, энергиясен кая куярга белмәгән егет - кызларны төрле чатаклыклар сагалап кына тора. Әлбәттә, эшкә урнашып бераз акча эшләргә күпләр каршы түгел. Ләкин заманы башка...Шулай да теләге булганнарга һәм кыек якка таба кереп китәргә маташкан егетләргә бу мәсьәләдә кайбер учреждениеләр һәм предприятиеләр саллы ярдәм күрсәтәләр. Район хакимияте каршындагы яшүсмерләр эше буенча комиссия тарафыннан шәһәрдә 80нән артык яшүсмер төрле оешмаларга эшкә урнаштырылды. Июнь аеннан бирле РСУда 40лап, "53нче СМУ" да 14 балигъ булмаган егет, "Сельхозтехника"да, 1нче ПМКда берәр бригада эшләде. Яшүсмерләр эше буенча комиссия рәисе Т.Ш.Гәрәева әйтүенчә, башка елларда да шул ук оешмалар балаларны эш белән тәэмин итүгә ризалык белдерәләр иде. Ә менә "Нурлатнефть" НГДУсы кебек куәтлерәк, баерак предприятиеләр яшүсмерләр белән бернинди бәйләнешкә кермәү ягын карыйлар булып чыкты. Хәер, эш бит түләүгә сәләтле булуда түгел, чөнки яшүсмерләргә хезмәтләре өчен РФның ике минималь хезмәт хакы күләмендә хезмәт һәм мәшгульлек бюросы түли. Балаларның күбесе исә аз керемле, күп балалы гаиләләрдән һәм милициядә исәптә торучылар арасыннан җыелган. Ә менә авылларда шул ук түләү юлы белән эшләүче яшүсмерләр гадәти гаиләләрдән, аларның саны тагын да күбрәк - барысы 700ләп укучы. Алар ремонт бригадаларында, хуҗалыктагы башка эшләрдә булышып йөрделәр һәм бүген дә эшләрен дәвам итәләр.

# "ЯШҮСМЕР СИНЕҢ КУЛДА, МӘКТӘП !"

Соңгы елларда мәктәпләр теләк белән укымаучы, начар өлгерешле, тәртибе канәгатьләнмәслек балаларны 10нчы класска кадәр генә җиткерәләр дә, тизрәк алардан арынырга тырыша башлаган иделәр. Моңа ризалык бирелүе бирелгән дә, ләкин баланың мәктәптән соңгы язмышы турында уйланылмаган булып чыга: нәтиҗәдә, башлыча, контрольсез, күзәтүчесез калган яшүсмерләр өчен тайгак юлга басу - җинаятьчелеккә тартылуга, наркотик матдәләр кулланучылар арасына керергә юл ачыла. Яшүсмерләр эше буенча комиссия практикасында ата - аналарның мәктәп директорларына, укытучыларга карата шикаять белән килү очраклары бар: алардан икенчеләренең балаларны 10-нчы класска алмас өчен ата - аналарга шактый басым ясаулары мәгълүм булды. Комиссиянең чираттагы утырышында бу мәсьәлә аерым игътибар үзәгендә иде. Анда шәһәр мәктәпләре директорлары чакырылды. Нык лы сөйләшүдән соң утырыш шундый нәтиҗәгә килә: укучының үз, ата - анасы ихтыярыннан башка аны 10нчы класска бару хокукыннан мәхрүм итмәскә кирәк. Өлгереше, тәртибе нинди булуга карамастан, яшүсмергә мәктәптә укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирелергә тиеш - утырышта катнашучы район хакимияте башлыгы урынбасары Н.Х.Абдуллинның ныклы карары шундый булды.

**Ф.ГАЛИМОВА.**

*Барыбызга да кагыла*

# САЛЫМ ИНСПЕКТОРЫН... ӨРКЕТМӘГЕЗ

***Бу язманың исеме кайберәүләргә уйлап чыгарылган, кахкаһә беләнрәк әйтелгән булып тоелырга мөмкин. Һәм без бу сүзләрне бары бер, туры мәгънәсендә генә аңлауларын теләр идек. Һәм менә ни өчен.***

Салым инспекторларының исләрен китерә торган бихисап күп мәсьәләләр бар. Юридик һәм физик затлардан алына торган салымнардагы аерма, мәсәлән. Беренчеләреннән казнага керергә тиешле сумманы ничек тә каерып алырга мөмкин әле, ә менә икенче төркем белән эш итүе - мең бәла.Җитмәсә, әҗере күпме генә бит әле шуның. Әйтик, былтыр гражданнардан җирле бюджетка 261 мең сум акча керде. Уртакул бер предприятиенең милек салымы кадәр генә бит бу. Ә шул сумманы җыйнап алу өчен түгелгән көчкә бәрабәрме соң ул? Салым инспекторларын нәкъ менә шунысы "таң калдыра" да инде: шул юк кына акчаны да халыктан җыеп алу өчен күпме нервы туздырырга, күпме вакыт сарыф итәргә туры килә бит.

Менә минем салым түлисем бар бит әле дип салым инспекциясенә үзләре килүчеләр бик сирәк шул. Киресенчә, күпләр әле өйләренә махсус кәгазь җибәргәннән соң да бик ашыкмый. Һәм салымчыларга халыкның исенә кабат - кабат төшереп торырга туры килә. Шулай итеп, дәүләт казнасын тутыру салым инспекторларының җилкәсендә, юк ла, аягында булып чыга. Туры мәгънәсендә шулай. Нәкъ менә шуңа да язмабызның башына куелган исемнең урынлы икәнлеген тагын бер кат искәртәсе килә: гражданнар, зинһар өркетмәгез салым инспекторын.

Югыйсә кайчагында менә болай да булып чыга бит. Салым җыючы хатын - кыз олы яшьтәге берәүнең өенә килә. Ишек шакуга җавап бирүче булмагач, кыяр - кыймас кына бусагадан эчкә үтә, алгы бүлмәләрдә кеше - мазар күренмәгәч, түргә үк уза һәм караватта яткан картны күреп, йоклый ахрысы дип, кычкырыбрак сүз ката. Җавап ишетмәгәч, картны уятырга дип җилкәсенә кагылса,... теге инде суынырга ук өлгергән - бернинди ашыгыч ярдәм дә булышырлык калмаган. Яки менә икенче очрак. Бу юлы инде ир - ат инспектор Нурлатның икенче башында яшәүче бер салым түләмәүчене эзләп китә. Хуҗаларны өйдә туры китерүенә шатланган инспектор ишегалдына керсә, анда хуҗа хатын бар дөньясын онытып кер юып ята. Дөньясын онытып диюебез юкка түгел, чөнки хатын... шәп - шәрә була. Чит ир - ат килеп керүдән читенсенми дә хәтта, киресенчә, инспектор үзе уңайсызлануыннан кая керергә урын таба алмый аптырап кала...

Ә берьюлы менә... Хәер, физик затлардан салым җыю бүлегендә эшләүчеләр мондый хәлләрне бик күп китерә алалар. Тик бүген сүз алар хакында түгел, ә тиешле икәнсең, түләргә һәм вакытында түләргә кирәклеге турындагы гап - гади хакыйкатьне гап - гади (кайчагында бик үк гади дә түгел) кешенең аңына ничек сеңдерү хакында. Вакыт дигәндә, салымны икегә бүлеп - 15 сентябрьгә кадәр һәм 15 ноябрьгә кадәр түләү срогы куелган. Шуннан сузасың икән - үзеңә үпкәлисең - көн саен 0,3 процент күләмендә пеня өстәлә башлый. Дөрес, бу инде салым түләүчеләр реестрына кертелгән кешеләргә генә кагыла, ә беренче тапкыр салым түләүгә тартылучыларга карата пеня мәсьәләсендә ташлама ясала.

Бу язманы ничек кенә зәһәрле көлү белән үткәрәсе килсә дә булмый: дәүләт куркыныч астында, казнаны ничек тә тулыландырырга кирәк дип тәкърарлап торалар бит. Цивилизацияле дөньяда бюджет фәкать физик затлардан җыела торган салымнар исәбенә тотыла диләр. Бәлки шулайдыр...

Ә менә бездә, мисал өчен, шәһәр буенча физик затларның өчтән бере генә диярлек милек салымы түли, калганнары - моннан тулысынча яки өлешчә азат ителгән. Дөрес, салымчылар ул льготалы чорның бер узасына инанганнар һәм ул чакта халык ни эшләр микән, карарбыз әле, диләр. Димәк, салым түләүчеләрнең "шатлыктан" кулларын чәбәклисе көннәре алда икән әле...

**Д.ТЯМАЕВА.**

*Редакциягә хат килде*

## КАДЕРЛЕ КЕШЕБЕЗ

Әни... Аның белән күпме кадерле, якты мизгелләребез бәйләнгән. Аңа безнең шатлыгыбыз да, хәсрәтебез дә сыйды, кайгы килсә тынычландыра да белә иде ул, күңелебез булганда ихластан куана, көлә дә белә иде. Безнең әниебез, Клавдия Евгеньевна Маслова, һәрвакыт игелекле, юмарт һәм ярдәмчел, тормыш сөючән кеше иде. Кешеләрне ярату, хөрмәтләү, җаваплылык кебек сыйфатларны бездә нәкъ ул тәрбияләде дә.

Әниебезнең сәламәтлеге әйбәт булмады. 1996 елның 16нчы мартында ул район үзәк хастаханәнең реанимация бүлегенә килеп эләкте. Ул чакта үз һөнәренең осталары, табиблар В.С.Ефремов, А.В.Слепцов, В.Г.Әбделманов, Х.Х.Мингалиев, Р.Х.Фәттахова, Р.Н.Әхмәтшина, И.Б.Солтанов ярдәмендә гаиләбез тагын аның белән аралашу бәхетенә иреште. Кызганычка каршы, чир китмәде, озакламый ул үзен тагын сиздерде. Бу елның 3нче июлендә әниебез авыр хәлдә тагын хастаханә койкасына яткырылды һәм табиблар тагын аның гомере өчен көрәшә башлыйлар. Ләкин чир үзенекен итте һәм 31нче июльдә кадерле кешебез дөньядан китте.

Без мәрхәмәтле, алтын куллы табибларга, шәфкать туташларына һәм санитаркаларга олы рәхмәтебезне җиткерәбез! Шундый авыр көннәрдә Римма Хавилевна Фәттахова безнең яныбызда торды. Гаҗәеп түземлелек, шәфкатьлелек күрсәтеп ул әниебезгә авыртуга түзәргә ярдәм итте. Рәхмәт аңа.

...Кеше гомере шундый кыска. Ә риясызлык һәм ярдәм никадәр кыйммәт.

**МАСЛОВЛАР,**
**Нурлат шәһәре.**

